ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17 октябрь 2024ел

№ 6847

Башкарма комитетның «Шәһәр җир өсте электр һәм автомобиль транспортында даими муниципаль маршрутлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару максатында Яр Чаллы шәһәре бюджетыннан субсидия бирү турында» 2024 елның 22 мартындагы 1779 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24, 5.25 пунктлары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Шәһәр җир өсте электр һәм автомобиль транспортында даими муниципаль маршрутлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару максатында Яр Чаллы шәһәре бюджетыннан субсидия бирү турында» 2024 елның 22 мартындагы 1779 номерлы Карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктта «30 000,0» цифрларын «26 211,27» цифрларына алмаштырырга;

2) шәһәр җир өсте электр һәм автомобиль транспортында даими муниципаль маршрутлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару максатында Яр Чаллы шәһәре бюджетыннан субсидия бирү тәртибендә 58 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«58. Субсидия алучы тарафыннан субсидия биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган очракта, шул исәптән Башкарма комитет һәм дәүләт (муниципаль) финанс контроле тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланганда, шулай ук субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешелмәгән очракта, субсидия алучыга карата субсидияне шәһәр бюджетына кире кайтару рәвешендә җаваплылык чарасы күрелә.

Субсидия бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе бозылу һәм (яки) әлеге Тәртипнең 44 пункты белән каралган нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешмәү ачыкланган очракта, Башкарма комитет өч эш көне эчендә субсидия алучыга

кимчелек турында белдерү кәгазе һәм субсидияне шәһәр бюджетына кире кайтару турында таләп җибәрә.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы — И.С. Зуев